# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
# ШӘРБӘН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАР

№ 8
19.10.2015 ел

**Татарстан Республикасы**
**Аксубай муниципаль районының Шәрбән авыл җирлеге**
**Советының 2011 елның 20 декабрендәге**
**«Бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында»**
**12 номерлы карарының аерым нигезләмәләрнең**
**амәлдә булуын туктатып тору турында**

«2016 елга Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары проектларын төзү һәм раслау үзенчәлекләре турында, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм «Россия Федерациясе Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында» Федераль законның 3 статьясын үз көчен югалтуын тану хакында " 30.09.2015 № 273-ФЗ Федераль законны үтәү йөзеннән Аксубай муниципаль районы Шәрбән авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. 2016 елның 1 гыйнварына кадәр Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Шәрбән авыл җирлегенең 20.12 карары белән расланган «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Шәрбән авыл җирлегендә бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында» нигезләмәнең 6.3 пункты, 8.2 пункты, 9 пунктының гамәлдә булуын туктатып торырга. 2011 ел № 12 Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Шәрбән авыл җирлеге бюджеты проектын план чорына төзү һәм раслау, күрсәтелгән проект белән бер үк вакытта Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Шәрбән авыл җирлеге советына документлар һәм материаллар тапшыру (Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Шәрбән авыл җирлегенең социаль-икътисади үсеш фаразыннан, бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләреннән тыш).

2. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга http://Aksubayevo.tatarstan.ru

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәрбән авыл җирлеге вәкиллекле органының план-бюджет комиссиясенә йөкләргә.

Аксубай муниципаль районы
Шәрбән авыл җирлеге башлыгы — Д.А. Шәрифуллин

СОВЕТ ЩЕРБЕНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ